## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**24 ноябрь 2022 ел** **№2**

2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Бүләк торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге Бүләк торак пунктында гражданнар җыены

### КАРАР ИТТЕ:

1. Сез 2023 елда Сарлы авыл җирлеге Сөендек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, 1500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 750 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Торак пункт чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобиле йөртүчесенең хезмәтенә түләү, ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү автомобиле өчен запас частьләр сатып алу, янгын депосын агымдагы ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу);
- Бәйрәм чараларын оештыру өчен шартлар тудыру һәм бәйрәм чараларын уздыру ("Җиңү көне", "Сабантуй", "Халыкара өлкәннәр көне", "Инвалидлар декадасы", "Яңа ел" бәйрәмнәренә бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу, милли бәйрәмнәр өчен реквизитлар алу (яңа ел чаналары, Сабантуй өчен арба), чараларны уздыру өчен аппаратура һәм инвентарь алу (4*8 мябык павильон, рамлы түбә));
- Авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру (Бүләк авылы мәдәният йорты өчен урам бәдрәфе сатып алу, чүплекләрне рекультивацияләү, балалар өчен уен аттракционнары һәм спорт инвентаре сатып алу, үләнне механикалаштырылган чабу һәм триммер сатып алу, Сабантуй мәйданын төзекләндерү (капка, койма кую, сәхнә урнаштыру, баганаы алыштыру, утыру урыннары ясау, бакча бәдрәфе сатып алу), МТЗ-82 өчен асылмалы җиһазлар сатып алу (көрәк, сәнәк, КУН-10, щетка) һәм булган җиһазлар өчен (чапкыч, отвал) запас частьләре сатып алу, Бүләк авылы мәдәният йортына кул насосы белән скважина урнаштыру, Бүләк авылы мәдәният йортын коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу, юлларны кардан чистарту);
- Бүләк авылы зиратларын карап тоту (8 куб. м ябык бункер алу, койма белән 3*4 контейнер мәйданчыклары урнаштыру, зиратларны чистарту).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сарлы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге башлыгы Л.М.Хаҗиев